КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 декабрь г.Казань № 1171

Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар салган зыяннар авырлыгын киметү чараларын тормышка ашыру турында

«Имин сыйфатлы юллар» илкүләм проектын гамәлгә ашыру һәм юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар салган зыяннар авырлыгын киметү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Республика башкарма хакимият органнарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына аларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә: квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, Татарстан Республикасының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясе секретариатына бу карар белән күздә тотылган чараларны тормышка ашыру турында хисап кертүне.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә аларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

һәлакәт булуны анализлау нигезендә федераль һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында «Шериф-балка» һәм юл-патруль хезмәтенең патруль автомобильләре макетларын урнаштыруны дәвам итүне;

төзелеш, реконструкция, капиталь ремонт яки ремонт объектларына проект документациясен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсенә карауга җибәрүне;

2025 елның 1 июленә кадәр федераль һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында юл билгесен (шул исәптән 1.14.1 «Җәяүлеләр юл аша чыгу урыны»

горизонталь билгесен) яңартып бетерүне;

2025 елның 1 июленә кадәр гомуми әһәмияттәге автомобиль юлларының авария-куркыныч участокларында делиниаторлар (юл сигналлары баганаларын) урнаштыруны оештыруны;

2025 елның 1 августыннан 28 августына кадәр белем бирү оешмалары янындагы җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарында 1.14.1 «Җәяүлеләр юл аша чыгу урыны» горизонталь билгесен яңарту чараларын башкаруны;

юл-төзелеш эшләре башкарыла торган урыннарда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән (шул исәптән тавыш полосаларын, «Шериф-балка»ны, светодиодлы индикациясе булган юл билгеләрен, Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерү комплекслары муляжларын куллану) чаралар комплексын гамәлгә ашыруны;

түбәндәге эшне дәвам итүне:

дүрт полосалы автомобиль юлларын кара-каршы килә торган хәрәкәт юнәлешләрен бүлү системалары белән җиһазлау, шулай ук юл аша чыгу каралмаган урыннарда җәяүлеләрнең транспорт йөри торган юлга чыгуын чикләү өчен катнаш җәяүлеләр коймаларын урнаштыру;

җәяүлеләрнең җир өстеннән юл аша чыгу урыннарына, юл чатларына якынаю урыннарына һәм гомуми әһәмияттәге автомобиль юлларының авария куркынычы булган участокларга аркылы тавыш полосаларын һәм транспорт чараларының читкә чыгып каплануын булдырмау максатларында машина юлы кырые буйлап буйлы-буйлы тавыш полосаларын урнаштыру;

беренче чиратта торак пунктлардагы мәгариф оешмалары, җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары, җәмәгать транспорты тукталышлары янында, автомобиль юлларының авария куркынычы булган участокларында автомобиль юлларын ясалма яктыртуны булдыру һәм машина йөри торган юл өстенә кабатлана торган 5.19.1 «Җәяүлеләр юл аша чыгу урыны» юл билгеләрен урнаштыру;

җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары буенча мәгълүмат бирүне арттыру, шул исәптән светодиодлы яктылык белән юл билгеләре куюны, өстәмә яктырту, проекция билгеләрен куллануны күздә тотарга;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә:

2025 елның 1 мартына кадәр автомобиль юлларының авария куркынычы булган участокларын, авария хәлендәге зоналарны, юл-транспорт һәлакәтләре күпләп булуы мөмкин булган урыннарны һәм юл-транспорт һәлакәтләре сирәк һәм үлүчеләре булган юллар участокларын бетерү чараларын эшләүне һәм 2025 елның 1 июленә кадәр аларны бетерү буенча планлаштырылган чараларны (реконструкция, капиталь ремонт һәм ремонт эшләре составына кертелгән чараларны – контрактларда билгеләнгән срокларда) төгәлләүне;

2025 елның 1 маена кадәр түбәндәге участокларны билгеләргә:

каршы як хәрәкәт полосасына чыгуга бәйле юл-транспорт һәлакәтләрен исәпкә алып, тавыш эффекты белән юл сызыгының күчәр сызыгын сызу; 2024 елның 15 июленә кадәр планлаштырылган чараларны үтәп бетерергә;

кара-каршы бәрелешләр булган автомобиль юллары участокларына һәм авария

куркынычы булган чатларга якынайган урыннарга мәгълүмат такталарын куллану; 2025 елның 1 июленә кадәр планлаштырылган чараларны үтәп бетерергә.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

белем бирү оешмалары һәм «йорт – мәктәп – йорт» балалар хәрәкәте маршрутлары буенча урам-юл челтәре янындагы җитешсезлекләрне бетерү чараларын юл эшләре планына Татарстан Республикасының юл фонды акчасы һәм муниципаль юл фондлары акчасының калган өлеше исәбеннән даими нигездә кертүне күздә тотарга;

җайга салынмый торган юл чатларына светофор объектларын урнаштыруны һәм әйләнеп хәрәкәт итүне оештырырга;

2025 елның язгы чорында хәрәкәтне вакытлыча чикләүне оештыру буенча кирәкле чаралар күрергә;

2025 елның 1 маена кадәр тизлекне мәҗбүри киметтерә торган чаралар эшләү участокларын билгеләргә һәм 2025 елның 1 сентябренә кадәр аларны (шул исәптән җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары белән янәшә булган ясалма тигезсезлекләрне) урнаштыру чаралары планын гамәлгә ашырырга;

балалар төркемнәрен оештырылган рәвештә йөрткәндә көн саен автобусларны, шулай ук мәктәп автобусларын эксплуатацияләү мониторингын үткәрергә һәм атна саен кызыксынучы республика башкарма хакимият органнарына алардан файдалану мөмкинлеге торышы, тизлек режимы үтәлеше турында мәгълүмат тапшырырга;

төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеге чаралары планын үтәү кысаларында тротуарлар эшләүне оештырырга;

«Россия Федерациясендә җиңел таксилар белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында, Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында һәм Россия Федерациясе закон чыгару актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 29 декабрендәге 580-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозган пассажирлар йөртүчеләргә һәм таксига заказ бирү хезмәтләренә (агрегаторларга) карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә контроль (күзәтчелек) чараларын оештырырга;

2025 елның 1 июленә кадәр гомуми әһәмияттәге автомобиль юлларының авария куркынычы булган участокларда трос киртәләре урнаштыру буенча тәкъдимнәр кертергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә:

пассажирларны законсыз йөртү фактларын туктату буенча профилактик чаралар үткәрүне оештырырга;

2025 елга юл эшләре программасын үтәү кысаларында мәктәп автобуслары маршрутлары уза торган автомобиль юлларының техник һәм эксплуатация күрсәткечләрен арттыру чараларын гамәлгә ашыруны;

түбәндәгеләр белән:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә, 2025 елның 1 мартына кадәр муниципаль юл фондлары акчасының үзләштерелми

калган өлешен юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча беренчел чираттагы чараларны үтәүгә җибәрү турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, 2025 елның апреленә кадәр юл-транспорт һәлакәтләре аркасында төзек булмаган яисә зыян күргән йөк транспорт чараларын автомобиль юлларыннан алар өсләренә менми торган куркынычсыз урыннарга (махсуслаштырылган урыннарга) күчерү, шулай ук табигать күренешләре һәм техноген характердагы һәлакәтләр салган зыяннарны бетергәндә машина йөри торган юлдан һәм җир полотносыннан йөк транспорт чараларын алу максатларында йөк транспорт чараларын эвакуацияләү өчен билгеләнгән ике эвакуатор сатып алу мөмкинлеген карарга;

Татарстан Республикасының автомобиль юлларын балансга тотучылар һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, һәлакәтләркә анализ ясау нигезендә Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерә торган комплексларны юл-транспорт һәлакәтләре күпләп була торган урыннарга күчерү буенча чаралар күрергә;

Татарстан Республикасының автомобиль юлларын балансга тотучылар белән берлектә, Татарстан Республикасында авария куркынычы булган юл чатларына һәм җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарына Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерә торган стационар комплексларын урнаштыру чараларын үткәрергә, шулай ук Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны терки торган күчмә чараларны (комплексларны) урнаштыру өчен урыннарны, шулай ук «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенең әлеге чаралар эшләвен тәэмин итүче белгечләр автотранспортлары өчен кереп туктау урыннарын җиһазландыру эшләрен оештырырга.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

яшь хәрәкәт инспекторлары арасыннан хәбәрчеләрнең массакүләм мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә юл-транспорт травматизмын профилактикалау һәм юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау буенча үткәрелә торган чаралар турында басмалар урнаштыру эшен оештырырга;

һәр мәгариф оешмасында юл хәрәкәте иминлеге турында социаль роликлар күрсәтә торган экраннар булдырырга;

түбәндәгеләрне дәвам итәргә:

мәгариф оешмалары эшчәнлегендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «www.sakla.ru» порталында урнаштырылган мәгълүмати материал-ларны куллану эшеен, шулай ук мәктәп укучыларына һәм аларның ата-аналарына әлеге ресурста юл хәрәкәте иминлеге буенча олимпиадаларда һәм викториналарда катнашуны тәкъдим итүне;

«Яшь юл хәрәкәте инспекторлары» юл хәрәкәтендә имин катнашу күнекмәләрен тәрбияләү буенча бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең төбәк бүлеген үстерүне;

белем бирү оешмаларында соңгы дәресләрдә «иминлек минутлары»ын

үткәрүне, шулай ук балаларга һәм ата-аналарга юлларда үз-үзеңне дөрес тоту буенча белем бирүгә, шул исәптән аларның яктылыкны кире кайтара торган элементларны йөртүен һәм балаларны тотып тора торган җайланмаларны һәм куркынычсызлык каешларын файдалануга юнәлдерелгән чаралар (дәресләр, әңгәмәләр һәм инструктажлар) үткәрүне;

түбәндәгеләр белән:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә:

шәһәр яны һәм мәктәп яны лагерьлары чаралары планында юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау һәм, «Куркынычсызлык лабораториясе» техник һәм методологик инструментларның күчмә комплексын кулланып, яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары эшчәнлеген популярлаштыру акцияләрен күздә тотарга;

«Имин көпчәк» яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары конкурсы, яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядларының профильле сменасы, «Мин яшь юл хәрәкәте инспекторларын сайлыйм» («Я выбираю ЮИД) дигән яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары форумы кебек республика чараларын үткәрергә;

мәгариф һәм яшьләр оешмаларында юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау һәм балалар юл-транспорт травматизмын профилактикалау чараларын үткәрүдә ирекле эзләү-коткару отрядларына ярдәм итәргә;

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан конкурслар (смотрлар, ярышлар, олимпиадалар) уздырганда аларга юл хәрәкәте куркынычсызлыгы тематикасы буенча номинацияләр яисә этаплар кертүне күздә тотарга;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасының яшь юл хәрәкәте инспекторлары матбугат үзәкләренең журналистлар корпусына керүче яшь юл хәрәкәте инспекторларына методик һәм гамәли ярдәм күрсәтергә;

«Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә:

белем бирү оешмаларын юл хәрәкәте иминлегенең заманча методик материаллары һәм җайланмалары белән тәэмин итүне дәвам итәргә;

2025 елның 1 сентябренә кадәр гомуми белем бирү оешмаларының беренче сыйныф укучылары арасында яктылыкны кире кайтара торган элементлар сатып алуны һәм таратуны оештырырга;

2025 ел дәвамында мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иҗтимагый тәртипне тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «Иҗтимагый тәртипне тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт программасы) кысаларында алынган юл хәрәкәте иминлеге җиһазларыннан файдалану нәтиҗәлелеген тикшерергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетлары белән берлектә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2021 елның 10 августындагы

280/под-1023/21 номерлы уртак боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында яшь юл хәрәкәте инспекторлары хәрәкәтен үстерү концепциясе нигезендә яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары эшчәнлеген оештырырга;

яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары эшчәнлеген үстерү белән шөгыльләнүче педагоглар өчен өстәмә финанс бирүне тәэмин итәргә;

балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмаларының чаралар планында юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау һәм яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары эшчәнлеген популярлаштыру буенча акцияләр күздә тотарга;

көн саен түбәндәгеләрне контрольдә тотуны оештырырга:

мәктәп автобуслары белән балаларны оештырылган рәвештә йөртү, шул исәптән «ГЛОНАСС» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган тахограф һәм борттагы навигация җайланмалары эшләве таләпләрен саклауны;

балаларның Юл хәрәкәте кагыйдәләре нигезендә һәм балалар хәрәкәтенең куркынычсыз маршрут схемалары нигезендә хәрәкәт итүен;

укучыларының яктылыкны кире кайтара торган элементларны йөртүен һәм ата-аналар җыелышларында һәм сыйныф сәгатьләрендә аларны куллану кирәклеге турында искәртүне.

5. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә:

балаларның һәм яшүсмерләрнең массакүләм ял итү вакытында, шул исәптән балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмаларында балаларның юл-транспорт имгәнүләрен кисәтү буенча профилактик белем бирү чараларын (тематик кичәләр, уеннар, юлларда үз-үзеңне дөрес тоту күнекмәләренә интерактив өйрәтү) үткәрергә;

Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнарында балалар ялы һәм аларны сәламәтләндерү оешмаларында яшь юл хәрәкәте инспекторларының профильле сменаларын оештыру өчен ел саен финанслауны күздә тотарга;

җәйге чорда «Камский Артек» балалар һәм яшүсмерләр ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру үзәге (Түбән Кама муниципаль районы) базасында «Имин көпчәк» яшь юл хәрәкәте инспекторлары конкурсының район этабы призерларының республика профильле сменасын, шулай ук яшь юл хәрәкәте инспекторларының «Мин яшь юл хәрәкәте инспекторларын сайлыйм» («Я выбираю ЮИД») дигән республика форумын үткәрүне оештырырга, ел саен әлеге чараларны оештыруга финанс бүлеп бирергә.

6. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

юл-транспорт һәлакәтләре салган зыяннарны бетерүгә җәлеп ителә торган көчләрне һәм чараларны үз вакытында әзер хәлгә китерү һәм оператив чара күрү максатларында, көн саен кызыксынучы республика башкарма хакимияте органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу турында оператив фараз тапшыруны оештырырга;

түбәндәгеләр белән:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, елга кимендә дүрт тапкыр, республика башкарма хакимияте органнарын җәлеп итеп, юл-транспорт һәлакәтләренә чара күрү буенча махсус тактик өйрәнүләр үткәрергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән, белем бирү оешмаларын максималь катнаштырып, «Тормыш иминлеге өчен юлларда иминлек» темасына тормыш иминлеге нигезләре буенча дәресләр уздырырга;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән берлектә, СМС-хәбәр итү юлы белән һава шартлары начараю һәм гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуның оператив фаразы турында халыкка хәбәр итү буенча кәрәзле элемтә операторлары белән эшне дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, 2025 елның 1 февраленә кадәр, бәяләр артуга бәйле рәвештә, агымдагы инфляцияне исәпкә алып, 2025 елда юл-транспорт һәлакәтләре салган зыяннарны бетерүгә җәлеп ителә торган Татарстан Республикасы янгыннан коткару, һәлакәттән коткару бүлекчәләрен заманча техника, һәлакәттән коткару кораллары һәм җиһазлары белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында өстәмә финанс бирү турында тәкъдимнәр әзерләргә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

зыян күрүчеләрне аз җиһазландырылган травма үзәкләреннән (2 һәм 3 дәрәҗә) һәм үзәк район хастаханәләреннән 1 дәрәҗә травма үзәкләренә транспорт белән алып бару өчен санитария авиациясен җәлеп итү нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар күрергә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, 2025 елның 1 сентябренә кадәр юл-патруль хезмәте хезмәткәрләре өчен «Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү һәм ярдәм әйберләрен куллану нәтиҗәлелеге» дигән уку курсы үткәрергә;

перинаталь үзәкләрдә юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау буенча тренинглар үткәрү тәҗрибәсен дәвам итәргә.

8. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына:

2025 елның 1 февраленә кадәр киносеанслар башланыр алдыннан кинотеатрларда юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча социаль реклама видеороликларын трансляцияләү мәсьәләсен карарга;

2025 елның 1 июненә кадәр юл хәрәкәте иминлеге темасы буенча балалар өчен спектакльләр булдыру һәм аларны Татарстан Республикасы театрлары репертуарына кертү эшен оештырырга.

9. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына:

өс киеме һәм аяк киеме җитештерүчеләр белән үз продукциясендә яктылыкны кире кайтара торган элементларны куллану турында мәсьәләне хәл итәргә;

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән берлектә, 2025 елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасында урнашкан

автомобильләргә ягулык салу станцияләрендә 16 яше тулмаган затларга ягулык сатуны тыю мәсьәләсен җентекләп эшләргә.

10. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, пилотсыз очу аппараты базасында автомобиль юлларының һәлакәт була торган участокларында файдалану өчен комплексны кертүне төгәлләү чараларын финанслау турында тәкъдимнәр әзерләргә.

11. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына, «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, экологик икеайлык чорларында Татарстан Республикасы автомобиль юлларындагы юл сервисы объектларының санитар-экологик торышын, бүленгән полосаларын һәм юл буе полосаларын контрольдә тоту эшен оештырырга.

12. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә, балаларга һәм яшүсмерләргә мототехниканы бары махсус трассада гына файдалану кирәклеге турында мәгълүмат бирүне оештырырга, шулай ук балаларны һәм яшүсмерләрне мототехника белән идарә итү күнекмәләренә өйрәтү буенча махсус спорт секцияләренә җәлеп итү мәсьәләсен җентекләп эшләргә.

13. «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тормыш эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» аерымланган структур бүлекчәсенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, түбәндәгеләрне дәвам итәргә:

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне «Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга юлларда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен өйрәтүнең заманча белем бирү технологияләре» программасы буенча укытуны;

яшь юл хәрәкәте инспекторлары отрядлары җитәкчеләре өчен уку-укыту семинарларын үткәрүне.

14. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына ел дәвамында:

массакүләм мәгълүмат чараларында түбәндәге материалларны бастырып чыгаруны тәэмин итәргә:

Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозып, каршыга килә торган полосага чыгарга, исерек хәлдә транспорт чаралары белән идарә итәргә, тизлек режимын арттырырга һәм зур зыян сала торган башка тупас хокук бозуларны кылырга ярамау турында;

балалар юл-транспорт травматизмын профилактикалау һәм тәүлекнең караңгы вакытында яктылыкны кире кайтара торган элементлардан файдалану зарурлыгы турында;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнардан машина йөртүчеләрнең исерек хәлдә һәм идарә итү хокукы булмаган яисә мондый хокуктан мәхрүм ителгән килеш транспорт чаралары белән идарә итү фактлары турында аноним мәгълүмат алу өчен телеграм каналын популярлаштыру турында;

автомобиль юлларының торышы, шул исәптән транспорт чараларының авырлыгын һәм габаритын контрольдә тоту һәм юл буе полосаларыннан файдалану өчен билгеләнгән тәртипнең үтәлеше турында;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасындагы проект офисы белән берлектә, гражданнарга социаль челтәрләрдә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча мәгълүмат бирү һәм алар белән аралашу эшен көчәйтергә.

15. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә:

транспорт чараларының авырлык-габарит параметрларын үлчәгәндә контроль-күзәтчелек органнарына булышлык күрсәтергә;

2025 елның язгы чорында хәрәкәтне вакытлыча чикләү кертү чорында транспорт чараларының үлчәү параметрларын үлчәүне тәэмин итәргә;

түбәндәгеләр белән:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, 2025 елның 1 мартына кадәр «ЭРА-ГЛОНАСС» системасының 330 берәмлек борт навигация-элемтә җиһазын сатып алу мөмкинлеген карарга;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, уку елы дәвамында һәм балалар һәм яшүсмерләр күпләп ял иткәндә балаларның юл-транспорт имгәнүен кисәтүгә юнәлдерелгән профилактик белем бирү чараларын үткәрергә;

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тотуның һәм үстерүнең төп идарәсе» дәүләт казна учреждениесе белән берлектә законнар бозып файдаланыла торган объектларны ачыклау, шулай ук Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының бүленгән полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә санкцияләнмәгән эшләрне ачыклау өчен урыннарга чыгарга.

16. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына:

Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссияләр утырышларын әзерләүдә һәм уздыруда катнашу эшләрен дәвам итүне;

2025 елның 1 мартына кадәр «Имин сыйфатлы юллар» милли проектын гамәлгә ашыру чорында юл-транспорт һәлакәтләре кылу сезоны нигезендә юл хәрәкәте кагыйдәләренең аерым бозуларны профилактикалау, «Юл хәрәкәте иминлеге» федераль проекты бурычларын исәпкә алып, 2025 елга оператив-профилактик чаралар уздыру календарен, «Яшәү өчен инфраструктура» илкүләм проектының «Юл хәрәкәте иминлеге» федераль проекты бурычларын исәпкә алып, актуальләштерүне;

«Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыятенең территориаль идарәләренә тимер юл аша чыгу урыннарын «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры килә торган тимер юл аша чыгу урыннарыннан үтү кагыйдәләрен бозуларны терки торган автомат системалары белән җиһазландыру чараларын үткәрүне;

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча баш

идарәсенә юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә 50 мең сумнан артык бурычы булган, шулай ук 50дән артык Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган затларга карата мәҗбүри характердагы чараларны үз вакытында куллану һәм административ йогынты ясау юлы белән административ штрафларны түләтү эшчәнлеген актуальләштерүне;

«Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә, «Автодор» дәүләт компаниясе һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) белән берлектә, 2025 елның 1 маена кадәр «Дистанцияне сакла» дигән юл билгесен сызу участокларын билгеләргә, 2025 елның 15 июленә кадәр планлаштырылган чараларны үтәп бетерергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының башкарма комитетларына:

2025 елның 1 июленә кадәр җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл билгесен (шул исәптән 1.14.1 «Җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары» горизонталь билгесен) яңартып бетерүне;

2025 елның 1 августыннан 28 августына кадәр белем бирү оешмалары янындагы җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарында 1.14.1 «Җәяүлеләр юл аша чыгу урыны» горизонталь билгесен яңарту чараларын башкаруны;

2025 елның 10 декабренә кадәр 2026 елда муниципаль әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тотуга муниципаль контрактлар төзүне;

индивидуаль мобильлек чаралары прокатын гамәлгә ашыруны планлаштырганда, 2025 елның 15 мартына кадәр, җәяүлеләр, транспорт чаралары һәм индивидуаль мобильлек чаралары хәрәкәте агымын бүлә торган тиешле юл инфраструктурасы булуын исәпкә алып, индивидуаль мобильлек чаралары прокатын гамәлгә ашыручы оешмаларга җир кишәрлекләре бүлеп бирү тәртибен билгели торган норматив базаны әзерләүне;

юлның нинди хәлдә булуына карап, рөхсәт ителмәгән массакүләм җәяүлеләр юл аша чыгу урыннарында светофор объектлары кую яки халык күпләп җәлеп ителә торган урыннарда ясалма тигезсезлекләр эшләү чараларын гамәлгә ашыруны;

2025 елның 1 июненә кадәр җәяүлеләрнең машина юлына санкцияләнмәгән чыгуын бетерү максатларында җәяүлеләр өчен киртәләр урнаштыруны алдан карауны;

2025 елга юл эшләре программасын үтәү кысаларында мәктәп автобуслары маршрутлары уза торган автомобиль юлларының техник һәм эксплуатация күрсәткечләрен арттыру чараларын гамәлгә ашыруны;

җәяүлеләр юл аша чыгу урыннары буенча мәгълүмат бирүне арттыру эшен дәвам итүне, шул исәптән светодиодлы яктылык белән юл билгеләре куюны, өстәмә яктыртуны, проекцияле юл билгеләрен куллануны күздә тотуны;

кар токтарлый торган калканнар урнаштыру һәм кар өемнәре була торган кишәрлекләрдә траншеялар булдыру мәсьәләсен өйрәнүне;

2025 елның 31 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең территориаль бүлекчәсе һәм «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең район филиалы белән массакүләм мәгълүмат чараларында юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау чараларын

яктырту буенча уртак планны раслауны;

район (шәһәр) конкурслары (смотрлар, ярышлар, олимпиадалар) үткәргәндә, аларга юл хәрәкәте иминлеге тематикасы буенча номинация яисә этап кертүне карауны;

кварталга кимендә бер тапкыр, муниципаль район башлыкларын, җирлекләр башлыкларын һәм балалар белем бирү оешмалары (мәктәпләр һәм балалар бакчалары) директорларын, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлларын балансta тотучыларны чакырып, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссиянең киңәйтелгән утырышын үткәрүне;

юл-төзелеш эшләре башкарыла торган урыннарда юл хәрәрәкте иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән (шул исәптән тавыш полосаларын, «Шериф-балка»ны, светодиодлы индикациясе булган юл билгеләрен, Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фотога һәм видеога төшерү комплекслары муляжларын куллану) чаралар комплексын гамәлгә ашыруны;

юл сервисы объектларының юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендәге законнар таләпләренә туры килмәвен билгеләгәндә бозуларны бетерү өчен объектлар милекчеләренә карата чаралар күрүне (мәгълүматны прокуратура органнарына яки судка дәгъва гаризалары җибәрүне);

«Зур габаритлы һәм (яки) авыр йөкләрне автомобиль белән ташуга махсус рөхсәтнамәләр бирү» системасының геомәгълүмат модуленә җирле әһәмияттәге автомобиль юллары турында мәгълүматны актуальләштерүне;

Татарстан Республикасы төбәк яисә муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының бүленгән полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә җир эшләре башкаруга килештерү ордерларын, кәгазьләрен килештергәндә «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесен һәм «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесен килештерүчеләр исәбенә кертүне;

балансta тотучылары булмаган автомобиль юллары участокларын балансkа алуны;

гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тотуга, юл билгеләре ясауга һәм чокырларга ремонт уздыруга озак срoклы контрактлар төзү мөмкинлеген карауны;

соңгы биш елда муниципаль берәмлек территориясендә юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгуны һәм алардан килгән зыяннарның авырлыгын кисәтүгә юнәлдерелгән карарлар кабул итеп авария хәленә анализ ясауны;

автотранспорт предприятиеләрендә машина йөртүчеләрне автобуслар белән идарә итүгә кертүне, шулай ук автобусларның техник торышын тикшереп торуны оештыру мәсьәләләрен карауны;

машина йөртүчеләрне исерек хәлдә автобуслар белән идарә итүгә кертүне төшереп калдыру максатларында мәктәп автобусларын эксплуатацияләүне контрольдә тотуны тәэмин итүне;

гражданнардан машина йөртүчеләрнең исерек хәлдә һәм идарә итү хокукы булмаган яисә мондый хокуктан мәхрүм ителгән килеш транспорт чаралары белән идарә итү фактлары турында аноним мәгълүмат алу өчен телеграм каналын

популярлаштыруны;

Россия милли машина йөртү таныклыгы булмаган чит ил машина йөртүчеләренең транспорт чаралары белән идарә итүгә кертелүен төшереп калдыру мәсьәләләрен карауны;

режимлы объектларда аларның вәкилләре катнашында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу куркынычсызлыгы мәсьәләләрен карап тикшерүне;

муниципаль берәмлекләрне төзекләндерү кагыйдәләренә «Юл сервисы объектлары» төшенчәсен һәм «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аларны тотуга таләпләр кертүне;

объектлар төзелешенә рөхсәтләр биргәндә, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы белән берлектә, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм юл эшчәнлеге хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы һәм «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы федераль законнар нигезләмәләрен исәпкә алып, автомобиль юлларының бүленгән полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә сервис һәм сәүдә объектларын урнаштыруга карата таләпләрне исәпкә алуны;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә (килешү буенча):

2025 елның 1 мартына кадәр юл-транспорт һәлакәтләре еш туплану урыннарын, авария хәлендәге зоналарны, юл-транспорт һәлакәтләре күпләп булуы мөмкин булган урыннарны һәм юл-транспорт һәлакәтләре сирәк һәм үлүчеләре булган юллар участокларын бетерү чараларын эшләүне һәм 2023 елның 1 июленә кадәр планлаштырылган чараларны (контрактларда билгеләнгән сроклар кысаларында реконструкция, капиталь ремонт һәм ремонт эшләре составына кертелгән чараларны) төгәлләүне;

автомобиль юлларын һәм юл корылмаларын төзеп, реконструкцияләп, капиталь ремонт яки ремонт ясап бетергәч, юл хәрәкәте иминлеге торышын бәяләү һәм аларны файдалануга тапшыру мөмкинлеге турында карар кабул итү максаты белән аларны тикшерүне;

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә:

кварталга кимендә бер тапкыр массакүләм мәгълүмат чараларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссияләр рәисләренең (шул исәптән юл-транспорт һәлакәтләре урыннарыннан) чыгышлар ясавын оештыруны;

даими рәвештә район массакүләм мәгълүмат чараларына суд залыннан фотолар белән исерек хәлдә идарә иткән өчен тоткарланган машина йөртүчеләр турында мәгълүмат җибәрүне;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетына 2025 елның 1 сентябренә кадәр «Камский Артек» балалар һәм яшүсмерләр ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру үзәге базасында юл хәрәкәте инспекторлары отрядларының ел саен үткәрелә торган профильле сменасын һәм яшь юл хәрәкәте инспекторларының «Мин яшь юл хәрәкәте

инспекторларын сайлыйм» («Я выбираю ЮИД») дигән республика форумын оештыруда катнашуны.

17. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен азайту һәм алар салган зыяннар авырлыгын киметү чараларын тормышка ашыру турында» 2023 ел, 19 декабрь, 1646 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

18. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенә һәм Татарстан Республикасының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясе секретариатына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин